ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

10.11.2015 Казан ш. № 474-к

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны (акча салуны) һәм булдыруны, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктының «и» пунктчасы, «Коррупциягә каршы торуның кайбер мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен вазыйфа биләгәндә Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Татарстан Республикасы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Шушы боерык кушымтасы булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә (алга таба – Идарә) вазыйфа биләгәндә

дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Идарәнең Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (Гатауллина А. Ф.):

- әлеге боерыкның 1 пунктында каралган исемлек белән кызыксынган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен таныштырырга;

- әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.11.2015 № 474-к боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

| № п/п | Вазыйфаның атамасы | Вазыйфалар саны | Вазыйфалар төркеме |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасы Баш дәүләт ветеринария инспекторы | 1 | югары |